Республика Татарстан

Совет Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

24.04.2025 Менделеевск ш. № 296

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
башлыгы һәм Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы Советы
депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы 6 өлешенең 2 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Уставының 31 статьясы, 37 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты, 42 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты, Беляев Радмир Илдар улының шәхси гаризасы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Беляев Ратмир Илдар улының Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башлыгы һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы депутаты вазыйфасыннан шәхси гаризасы нигезендә үз теләге белән отставкага китүен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башлыгы һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы депутаты Беляев Радмир Илдар улының вәкаләтләрен 2025 елның 23 апрелендә вакытыннан алда туктатылган дип санарга.

3. Әлеге карарны «Менделеевск яңалыклары» газетасында бастырып чыгарырга, Менделеевск муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

Совет рәисе урынбасары Л.К. Галеева